РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» ноябрь 2019 ел Олы Кайбыч ав. № 198

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Кайбыч муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм муниципаль район Уставының 92 статьясына, Кайбыч муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты проектын беренче укылышта кабул итәргә.
2. Кайбыч муниципаль районы Советының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты турында» карары проектын гавами тыңлауларга чыгарырга.
3. Кайбыч муниципаль районы Советының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты турында» карары проектын Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр сайтында http://kaybici.tatar.ru бастырырга.
4. Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча комиссиягә Кайбыч муниципаль районы Советының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты буенча килгән тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм карарга.
5. Кайбыч муниципаль районы Советының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты буенча 2019 елның 25 ноябрендә Кайбыч муниципаль районы Советының актлар залында гавами тыңлаулар үткәрергә.
6. Кайбыч муниципаль районы Советы Аппаратына һәм Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына күрсәтелгән карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Советы рәисе урынбасарына йөкләргә.

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин